**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2020 ел, 2 ноябрь №14

**«Апас шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә һәм Апас шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турында» гы карарга үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар **бирә** :

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 117 номерлы «Апас шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә һәм Апас шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү, муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада

1.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең максатлары өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча, "иминият пенсияләре турында" Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч йә вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә һәм тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«1.7.Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләү өчен, җирле үзидарә органына (алга таба – Башкарма комитет) (килешү буенча) түбәндәге документлар тапшырыла:

муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләүе турында белешмә;

муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәткәре тарафыннан раслаган белешмә;

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, тиешенчә расланган һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;

кадрлар хезмәте раслаган хәрби билетның күчермәсе (дәүләт хезмәткәрендә булганда);

класслы чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керүче вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында күрсәтмәләрдән өземтә;

муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.».

2.Әлеге карарны Апас шәһәр җирлеге мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка. йөкләргә.

**Апас муниципаль районы**
**«Апас шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы Урынбасары**
**Апас муниципаль районы –Апас шәһәр җирлеге**
**Советы Рәисе урынбасары** **Н.Т. Исмәгыйлев**